ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26. 05. 2022 Олы Кайбыч ав. № 241

Яшь гаиләләргә торак сатып алу (төзү) өчен бирелә торган социаль түләүләр күләмен исәпләү өчен 2022 елның II кварталына Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы буенча торакның бер квадрат метр гомуми мәйданының нормативын билгеләү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 03 октябрендәге 888 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү» ярдәмче программасын гамәлгә ашыру кысаларында яшь гаиләләргә торак сатып алу өчен социаль түләүләр бирү кагыйдәләренең 10 пункты нигезендә, ТР Бәяләүчеләр союзының эксперт-консультация советы тарафыннан үткәрелгән ТР Кайбыч муниципаль районында һәм Олы Кайбыч авылында торак биналарның бер квадрат метр бәясенең уртача күрсәткечен билгеләү буенча тикшеренү нәтиҗәләрен исәпкә алып («Бәяләр диапазонын билгеләү турында» 2002 елның 07 февралендәге 38 номерлы Коммерциясез партнерлыгы хаты), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 3 октябрендәге 888 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итү» дәүләт программасының «2020-2025 елларга Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы буенча торак шартларын яхшыртуга мохтаж дип танылган яшь гаиләләргә 2022 елның II кварталына торак сатып алу яки индивидуаль торак йорт төзү өчен социаль түләүләр күләмен исәпләү өчен бәя нормативын гомуми торак мәйданының бер квадрат метрына 31690 сум күләмендә билгеләргә.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Кайбыч

муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://kaybici.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең төзелеш һәм ТКХ буенча урынбасары Б.Р. Сәлаховка йөкләргә.

Җитәкче А.Н. Макаров